# Көзге иртәдә уйланулар

Көзге көн – матур көн! Сары төскә кергән агачлар арасыннан урам буйлап барганда,әбиләр чуагының шаян җиле биткә килеп бәрелә.Күктәге кояш та, яңгырлы көннәр киләсен сизеп, күбрәк яктыртып каласы килгәндәй,учлап – учлап нурларын чәчә. Шундый рәхәт урамда!

Шулай өскә карап,белем тупларга мәктәбемә барганда чак кына җыелып торган суга барып кермәдем.

Чу,тукта, нәрсә ялтырап ята анда?Алтын көзнең алтын бизәгеме? Юк,яфрак шулай ялтырый алмас ?!

Бәлки анда алкадыр ,әллә йөзекме?Килеп карагач ,5 сум тиен акча икәнен күрдем.

Бу 5 сум миңа авылдагы чишмәне искә төшерде.Анда чишмәгә вак тиеннәр аталар.Ул көмеш акчалар суны чистарта,тәмләндерә, дип әйтә минем әбием.Чишмәдән акча алырга ярамый,авыру ияреп кайта, дип тә өйрәтте ул мине.Ә бу акча чишмәдә түгел,юлда ята бит. Өйдән чыкканда,сул кулым кычыткач,акча керә ,дип сөенгән идем,шушыңа икән!Иии, син шуңа калганмы,5 сумга нәрсә тия инде,дип үземне эчтән генә тиргәп алдым.

Дөрес,бер карасаң,биш сум бик аз акча инде,ләкин аз да түгел.Шул 5 сум җитмәгәнлектән, дару ала алмаган кешенең гомере өзелергә мөмкин.”5 сум эшләгәнче, биш кат тирең чыга,улым”-дип әйтергә ярата минем әти.Шул вакыт ,кызгылт-сары яфраларны туздырып ,янымнан автобус узып китте.Автобуска да биш сумың җитмәсә утыртмыйлар.Уң кулымны кесәмә тыктым.Ә анда бер нәрсә дә юк,анда кечкенә тишек!Икенчесен карыйм,аллага шөкер, автобуска дигән акча шунда икән.Мин көлеп җибәрдем һәм өйгә кайткач үк ул кесәне тегеп куям, дидем.Ә салкын судагы 5 сумлык акча хуҗасын көтеп ятып калды...